Татарстан
Республикасы Милли
китапханәсе

# 2026 ел – Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы

Методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2026

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе

# 2026 ел – Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы

*Методик-библиографик ярдәмлек*

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2026

**УДК 021.4:37.035.7(083.1)**
**ББК 78.374 3я81**
**И 41**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият шурасы карары белән басыла

Төзүчесе З.Ә.Җамалиева

Мөхәррире И.Г.Һадиев

**И 41 2026 ел – Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы:** методик-библиографик ярдәмлек /Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә. Җамалиева; мөх-ре И.Г. Һадиев. – Казан: Милли китап, 2026. – 20 б.

Ярдәмлек Татарстан Республикасының Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш керткән шәһәрләре һәм предприятиеләренә, сугыш һәм тыл батырларына багышланган әдәбият белән эшләү өчен китапханәчеләргә тәкъдим ителә. Бирелгән материалларны әдәби кичәләр, фикер алышулар һәм башка мәдәни чаралар үткәрүдә файдаланып була.

**УДК 021.4:37.035.7(083.1)**
**ББК 78.374 3я81**

© Татарстан Республикасы
Милли китапханәсе, 2026;
© «Милли китап» нәшрияты, 2026.

## Кереш сүз

2026 ел Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы дип игълан ителде. Шушы уңайдан китапханәчеләр алдына бу елны, шушы темага да туры китереп, тиешенчә үткәрү бурычы куела. Китапханәләрдә төрле чаралар: сугыш һәм тыл ветераннары, Җиңүгә зур өлеш керткән предприятиеләр вәкилләре, сугыш чоры балалары белән очрашулар, китап күргәзмәләре, әңгәмәләр, китапларга күзәтү ясау, сугыш темасына багышланган шигырь һәм җыр кичәләре, конкурслары үткәрү, викториналар, батырлык дәресләре, квестлар, квизлар, остаханәләр уздыру тәкъдим ителә.

Бу максаттан чыгып, без сезгә методик ярдәмлек тәкъдим итәбез. Ярдәмлектә кайбер чаралар үткәрү өчен якынча үрнәкләр бирелә. Шулай ук Милли китапханәнең методик бүлеге төрле елларда чыгарган башка ярдәмлекләрдән дә файдалану киңәш ителә.

## Интернет-чыганаклар

https://gossov.tatarstan.ru/file/gossov/see_also/s8858569_3001.pdf фидакарь хезмәт һәм хәрби батырлык белән Ватанны данлыйбыз!

https://nsportal.ru/nachalnaya-shkola/vospitatelnaya-rabota/2016/01/14/syynyf-sgate-batyrlyk сыйныф сәгате: батырлык

https://infourok.ru/vneklassnoe-meropriyatiesezne-tormish-ze-batirlik-587176.html «Сезнең тормыш – үзе батырлык!» дигән исем белән сыйныфтан тыш чара

https://znanio.ru/media/klassnyj_chas_na_temu_batyrlyk_nrs_so_ul_batyrlyk-72294 «Батырлык! Нәрсә соң ул батырлык?» темасына сыйныф сәгате

https://teacher-rt.ru/index.php/biblioteka/klassnyj-rukovoditel/1760-n_rs_ul_batyrlyk

Нәрсә ул батырлык? (Ш.Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә» әсәре буенча йомгаклау дәресе)

https://open-lesson.net/2159/ Батыр үлә, үлмәс ат алып, батырлыклар белән макталып...: ачык дәрес

https://kazanutlary.ru/j-archive/journal-materials/2015-5/boek-vatan-sugyshy-xxi-gasyrdan-karash Бөек Ватан сугышы. XXI гасырдан караш

https://textarchive.ru/c-1254892-p39.html мәктәптә патриотик тәрбия

https://sabyem.ru/?p=9874 сценарий: «Тыныч булсын күгебез»

## Методик ярдәмлекләр исемлеге

1. Бар җырымны илгә багышладым...: татар халкының мәшһүр улы, каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең (Муса Мостафа улы Җәлилов; 1906–1944) тууына 120 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек/ Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Р.Р.Гаязова; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2025. – 48 б.

2. Билгесез сугыш=Неизвестная война: взгляд через 55 лет: методико-библиографические материалы / Национальная библиотека Республики Татарстан; сост. К.Б.Фатхеева; отв. ред. А.Р.Абдулхакова. – Казань: Милли китап, 1999. – 52 с.

3. Бөек Җиңүгә – 65 ел / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә.Җамалиева; җав. мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2011. – 48 б.

4. Бөек Җиңү: Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган методик-библиографик ярдәмлек /Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә.Җамалиева; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2025. – 32 б.

5. Была война..: сб. сценариев / Национальная библиотека Республики Татарстан; авт.-сост. Е.Г.Шемелова; отв. ред. А.Х.Мушинский. – Казань, 1996. – 40 с.

6. Габдрахман Әпсәләмов: әдипнең тууына 100 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Р.Р. Гаязова; җав. мөх-ре И.Г. Һадиев. – Казан: Милли китап, 2009. – 32 б.

7. Илең турында уйласаң – гомерең озын була...: күренекле татар шагыйре Фатих Кәримнең (1909–1945) тууына 110 ел тулуга

багышланган методик-библиографик ярдәмлек / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә.Җамалиева; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2018. – 24 б.

8. Каләм белән җиңдем дошманны: Бөек Ватан сугышында катнашкан татар язучыларына багышланган методик һәм библиогр. ярдәмлек / Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе; төз. Р.Хөрәмшина; җав. мөх-ре И.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2005. – 34 б.

9. Каләм белән җиңдем дошманны: Бөек Ватан сугышында катнашкан татар язучыларына багышланган методик һәм библиогр. ярдәмлек: тулыландырылган 2 нче басма / Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе; төз. Р.Р.Гаязова; җав. мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2010. – 36 б.

10. Муса Җәлил (1906–1944): шагыйрь һәм каһарман, азатлык көрәшчесе Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган методик һәм библиогр. ярдәмлек / Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе; төз. Р.Хөсәенова; җав. мөх-ре И.Һадиев.– Казан: Милли китап, 2005. – 26 б.

11. Үткән сугыш... / Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе; төз. Н.Ә.Асылкаева; җав. мөх-ре Р.И.Вәлиев. – Казан: Милли китап. 1996. – 46 б.

12. Яшәү белән үлем арасында: күренекле шагыйрь, прозаик, драматург һәм публицист Нәби Дәүлинең (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин; 1910–1989) тууына 110 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Р.Р.Гаязова; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2020. – 44 б.

УКАЗ
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
УКАЗЫ

**Об объявлении 2026 года в Республике Татарстан**
**Годом воинской и трудовой доблести**

В целях сохранения исторической памяти, укрепления гражданской солидарности и в знак уважения ко всем поколениям защитников Отечества и тружеников тыла постановляю:

1. Объявить 2026 год в Республике Татарстан Годом воинской и трудовой доблести.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан:
в месячный срок образовать организационный комитет по проведению в Республике Татарстан Года воинской и трудовой доблести и утвердить его состав;
в трехмесячный срок разработать и утвердить план основных мероприятий по проведению в Республике Татарстан Года воинской и трудовой доблести.

3. Предложить главам муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан организовать работу по проведению на территориях муниципальных образований мероприятий в рамках Года воинской и трудовой доблести.

4. Предложить территориальным органам федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, общественным объединениям и организациям принять активное участие в подготовке и проведении в Республике Татарстан Года воинской и трудовой доблести.

5. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» обеспечить широкое освещение проведения в Республике Татарстан Года воинской и трудовой доблести.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
17 октября 2025 года
№ 863

УКАЗ
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
УКАЗЫ

**2026 елны Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы дип игълан итү турында**

Тарихи хәтерне саклау, гражданнарның бердәмлеген ныгыту һам барлык буын Ватанны саклаучылар һам тыл хезмәтчәннәренә ихтирам йөзеннән карар бирәм:

1. 2026 елны Татарстан Республикасында Хәрби батырлъік һам хезмәт фидакарьлеге елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һам хезмәт фидакарьлеге елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елын уздыруның төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Хәрби батырлык һам хезмәт фидакарьлеге елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 17 октябрь
№ 863

## Татарстандагы хезмәт батырлыгы шәһәрләре

**<u>Казан</u>** (2020 елның 2 июлендәге Указ белән бирелгән статус) – сугыш вакытында биредә 139 сәнәгать предприятиесе хәрби максатларда эшләгән, шәһәр эвакуацияләнгән 70 ләп заводны кабул иткән, корал, самолётлар җитештергән.

**<u>Яшел Үзән</u>** (статус 2025 елның гыйнварында бирелә) – Горький заводы бронялы 117 катер, 13 су асты көймәсе һәм 9 елга көймәсе эшләп чыгарган, 4 миллионнан артык артиллерия снарядлары ясаган.

*Татарстан Хөкүмәтендә тагын дүрт шәһәргә исем бирү өчен документлар әзерләнә:*

***Чистай*** *(СССР язучылары һәм мәдәният әһелләре күпләп эвакуацияләнгән шәһәр);*

***Кукмара*** *(фронтны кием-салым һәм аяк киемнәре белән тәэмин иткән);*

***Алабуга;***

***Бөгелмә.***

«Хезмәт батырлыгы шәһәре» исеме Бөек Ватан сугышы чорында үз җирлегендәге хәрби һәм гражданлык предприятиеләрендә өзлексез җитештерүне тәэмин иткән шәһәрләргә бирелә. Аларда шәһәр гербы һәм Россия Федерациясе Президенты Указы тексты махсус ясалган стеллага беркетеп куела.

## Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының 27 предприятиесе «Хезмәт батырлыгы предприятиесе» исеменә лаек булды

**<u>Авиация һәм машина төзелеше:</u>**

– С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы (Туполев исемендәге АҖ филиалы);

– Казан вертолёт заводы;

– Казан моторлар төзү-җитештерү берләшмәсе (КМПО);

– Яшел Үзәннең А.М.Горький исемендәге заводы;

– «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе – ПОЗИС (Яшел Үзән шәһәре).

**<u>Оборона сәнәгате һәм химия:</u>**

– Казан дәүләт казна дары заводы;

– «Казан төгәл машиналар төзелеше заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе («Точмаш»);

– Казан оптик-механика заводы (КОМЗ);

– «ТАСМА» фәнни-җитештерү предприятиесе;

– Химия продуктлары дәүләт фәнни-тикшеренү институты – ГосНИИХП;

– М.Вахитов исемендәге Казан химия комбинаты – «Нәфис Косметикс» АҖ.

**<u>Электр техникасы һәм приборлар ясау сәнәгате:</u>**

– «Челтәр компаниясе» АҖ филиалы – Казан электр челтәрләре;

– «Радиоприбор» акционерлык җәмгыяте;

– Татарстан агач эшкәртү комбинаты;

– Казан электро техника заводы;

– Казан «Электро прибор» заводы;

– «Вакуммаш» ационерлык җәмгыяте;

– Чистай «Восток» сәгать заводы.

**<u>Товарлар һәм материаллар җитештерү:</u>**

– «Мелита» җитештерү берләшмәсе;

– Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы;

– Казан синтетик каучук заводы;
– Кукмара металл савыт-сабалар заводы;
– Кукмара киез-итек комбинаты;
– «Татхимфармпрепараты» акционерлык җәмгыяте;
– «Элекон заводы» акционерлык җәмгыяте;
– «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте;
– В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте;
– Б.И.Тихомиров исемендәге «Казан Гипроницавиапром» акционерлык җәмгыяте.

**Хезмәт даны елъязмасы**

(Летопись трудовой славы)

*Әдәбият исемлеге*

*(Список литературы)*

1. 130 лет верности морю: хроника становления и развития судостроительного завода имени А.М.Горького // Зеленодольская правда. – 2025. – 16 октября. – С. 3.

2. Абрамов К. Некоторые особенности тылового обеспечения / К.Абрамов // Военно-исторический журнал. – 1982. – № 11. – С. 62–69.

3. Барышников А. Труд, приравненный к подвигу / А.Барышников // Красная Татария. – 1945. – 24 июня. – С. 2.

4. В Сталинской фонд победы // Красная Татария. – 1944. – 11 февраля. – С. 1.

5. Величие духа // Советская Татария. – 1970. – 8 мая. – С. 3.

6. Велишкевич А. Все для фронта, все для победы! / А.Велишкевич // Комсомолец Татарии. – 1965. – 9 мая. – С. 2, 3.

7. Вклад Зеленодольска в общую Победу нашей страны неоценим // Казанские ведомости. – 2025. – 22 января. – С. 1.

8. Герои тыла Республики Татарстан = Татарстан Республикасы тыл геройлары / ГБУ РТ «Редакция «Книга Памяти»; [гл. ред. А.А.Иванов].– Казань: [Редакция «Книга Памяти»], 2015.– 333, [1] с.

9. Города трудовой славы // Профсоюзы – 2020. – № 7. – С. 3–13.

10. День, который войдёт в историю // Зеленодольская правда. – 2025. – 23 января. – С. 1, 2, 10–11.

11. Завод имени Серго: сто лет в строю: вековой истории завода посвящается... / автор предисловия Р.Ш.Хасанов. – Зеленодольск, 1998. – 207 с.

12. Залялова Г. Оплот обороны / Г.Залялова // Казань. – 2025. – № 8. – С. 91–99.

13. Здравоохранение Казани в годы Великой Отечественной войны // Казанский медицинский журнал. – 2012. – № 3. – С. 417–420.

14. История Казани / АН СССР, Казанский научный центр, Институт языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова. – Казань: Татарское книжное издательство, 1988. – Кн. 2 / [ред. коллегия: З.И.Гильманов, А.М.Залялов, М.К.Мухарямов и др.]. – 1991. – 381, [1] с.

15. К новым успехам, товарищи меховщики! // Красная Татария. – 1944. – 26 января. – С. 1.

16. Кабирова А. В годы испытаний / А. Кабирова // Казань. – 2005. – № 4. – С. 71–84.

17. Кашапова С. Хезмәт батырлыгы шәһәре / С. Кашапова // Мәдәни җомга. – 2020. – 17 июль. – Б. 5.

18. Корнеев М. Наступление в труде / М. Корнеев // Красная Татария. – 1943. – 22 сентября. – С. 3.

19. Кузнецов А. Трудовая доблесть /А. Кузнецов // Красная Татария. – 1943. – 30 апреля. – С. 2.

20. Маршрутами Победы // Зеленодольская правда. – 2025. – 8 мая. – С. 10–11.

21. Нуриев Р. Труд, приравненный к подвигу: деятельность Особого конструкторского бюро – 16 Казанского авиационного завода в годы Великой Отечественной войны / Р.Т.Нуриев // Эхо веков – Гасырлар авазы. – 2020. – № 1. – С. 37–50.

22. Они обеспечили нашу Победу //Республика Татарстан. – 2025. – 18 января. – С. 4.

23. Семёнова С. Память о военном поколении серговчан / С. Семёнова; автор предисловия Р.Ш.Хасанов (генеральный директор объединения [«Завод им. Серго»]). – Зеленодольск, 2000. – 260 с.

24. Сергеева О. Города трудовой доблести / О. Сергеева // Герои всех исторических эпох. – 2021. – № 6. – С.12.

25. Товарищ Орлов, Вас смотрит Москва! // Зеленодольская правда. – 2025. – 20 февраля. – С. 10–11.

26. Томан Б. Великая Отечественная: известное и неизвестное / Б. Томан // Вопросы истории КПСС. – 1990. – № 9. – С. 83–96.

27. Трудовой подвиг молодёжи Татарии в годы Великой Отечественной войны. 1941–1945 / под ред. А.Абдульзянова. – Казань: Издательский дом Маковского, 2022. – 128 с.

28. Туманская О. Хлеб и зрелища тыла // Татарстан. – 2015. – № 5. – С. 42–54.

29. Уроки истории. Эвакогоспитали // Здоровье нации. – 2020. – № 1. – С. 56–57.

30. Хамидуллин Л. Победа досталась дорогой ценой: [историко-публицистические очерки] / Л.Хамидуллин, Б.Хамидуллин; [науч. ред.: И.Тагиров, И.Гилязов; пер. с татар. Ч.Гариповой]. – Казань: Татарское книжное издательство, 2015. – 222, [1] с.

31. Худякова Р. Тыловые эвакогоспитали Татарии в годы Великой Отечественной войны / Р. Худякова // Казанский медицинский журнал. – 1985. – № 3. – С. 161–168.

32. Яшел Үзән – батырлык шәһәре // Ватаным Татарстан. – 2025. – 21 гыйнвар. – Б. 4.

**Шулай ук карагыз:**

Татарстан в годы Великой Отечественной войны: сборник электронных материалов: сайт / Национальная библиотека Республики Татарстан.

URL: https://kitaphane.tatarstan.ru/tat_vov.htm (Дата обращения: 24.02.2026).

Республиканские газеты военных лет: сайт / Национальная библиотека Республики Татарстан.

URL:https://kitaphane.tatarstan.ru/newspapers_vov.htm (Дата обращения: 24.02.2026).

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе сайтында «2026 ел Татарстанда “Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы” дип игълан ителде» (https://kitaphane.tatarstan.ru/tat/index.htm/news/2541771.htm) һәм «Летопись трудовой славы» («Хезмәт даны елъязмасы»; https://kitaphane.tatarstan.ru/index.htm/news/2516901.htm) дип аталган виртуаль күргәзмәләр куелган, алардагы материаллардан файдалана аласыз. Күргәзмәләрне Милли китапханәнең татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү, вакытлы матбугат бүлекләре әзерләгән.

## Тыл батырлары – Җиңү адымнары

*(Бөек Ватан сугышы елларында тылда хезмәт фидакарьлеге күрсәткән ветераннарны хөрмәтләү кичәсе)*

**Максат:** Тыл хезмәтчәннәренең Бөек Җиңүгә керткән өлешен билгеләп үтү, яшь буында Ватанга мәхәббәт һәм хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Сценарий барышы:**

**1. Кереш өлеш** *(Музыка астында алып баручылар чыга)*

**1 нче алып баручы:**

Хөрмәтле ветераннар, тыл хезмәтчәннәре, кадерле кунаклар! Сезне чын күңелдән якынлашып килүче бөек бәйрәмебез – Җиңү көне белән котлыйбыз!

**2 нче алып баручы:**

Бүген без сезнең алда баш иябез. Сезнең батырлык – ул 1941–1945 елларда фронттагыларны тәэмин итү өчен, көнне-төнне белмичә эшләү, фидакарь хезмәт!

**2. Төп өлеш: «Тылда эш – фронттагы батырлыкка тиң»**

**1 нче алып баручы:**

Сугыш елларында ир-атлар фронтка киткәч, авыр эшләр хатын-кызлар, картлар һәм балалар җилкәсенә төште. Алар иген үстерделәр, танк һәм самолётлар ясадылар, кием-салым тектеләр.

*(Сәхнәдә тыл хезмәтчәннәренә багышланган кечкенә театраль күренешләр яки шигырьләр укыла).*

**3. Бүләкләү һәм котлаулар**

**2 нче алып баручы:**

Хәзерге көндә тыл ветераннары һәм сугыш чоры балалары да аз гына калып бара. Алар – безнең тарихыбыз, безнең горурлыгыбыз.

*(Ветераннарга чәчәкләр, истәлекле бүләкләр тапшыру тантанасы).*

**4. Йомгаклау өлеше**

**1 нче алып баручы:**

Кадерле тыл батырлары! Сезгә нык сәламәтлек, озын гомер телибез. Сезнең хезмәт – Җиңүнең нигезе!

**2 нче алып баручы:**

Без сезнең батырлыкларыгыз турындагы истәлекләрне сакларга сүз бирәбез!

*(Бәйрәм концерты: сугыш чоры җырлары башкарыла)*.

## Сезнең тормыш үзе батырлык

*(Хатирәләр һәм мәдхия кичәсе)*

*Сәхнә чәчәкләр һәм тасмалар белән бизәлгән. Түрдә «Сезнең тормыш – үзе батырлык» дип язылган. Сәхнәнең бер кырыенда «Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакарь хезмәт өчен» медаленең макеты тора. Кунаклар өчен өстәлләр, урындыклар куелган, өстәлләрдә чәчәкләр.*

*Сәхнә ябык. Лирик көй ишетелә. Сәхнә ачыла. Көй акрыная. Ике алып баручы чыга.*

**1 а.б.** Исәнмесез, кунаклар, тыл батырлары!

**2 а.б.** Исәнмесез, авыл уңганнары! Исәнмесез, апалар-абыйлар, әтиләр-әниләр, әбиләр һәм бабайлар!

**1 а.б.** Бүген без, сезнең батырлыкларга яңадан бер кабат соклаcalled өчен, сезгә дан һәм мәдхия җырлар өчен һәм сезнең түземлегегез, сабырлыгыгыз алдында баш ияр өчен бу залга җыелдык.

**2 а.б.** Безнең бүгенге бәйрәмдә район җитәкчеләре катнаша. Сүзне *(Фәлән)*гә бирәбез. *(Чыгыш.)*

**1 а.б.** Хөрмәтле ветераннар, *(Фәлән)* башкаруында халкыбызның Нәкый Исәнбәт сүзләренә иҗат ителгән «Илкәем» җыры сезгә музыкаль сәламебез булып яңгырасын. *(Җыр.)*

**2 а.б.** Сезнең язмыш сугыш уты белән бергә үрелгән. *(«Изге сугыш» («Священная война» ) көе ишетелә. Көй яңгыравы астында шигырь укыла.)*

Ул елларны ничек онытасың,
Ил язмышы кылыч йөзендә.
Ир-егетләр китте яу кырына,
Алып көче тоеп үзендә.
Ирләр китте, кызлар елап калды,
Шаулап калды иген, өлгереп.
Басу капкасына чаклы озата барды
Яше, карты, барысы өзелеп.
Ирләр китте, кызлар елап калды,
Елап калды күпме хатыннар.
Туйда кигән күлмәкләре калды,
Күпме бала калды, ятимнәр. *(Музыка бетә.)*

**1 а.б.** Әйе, авылда картлар, хатын-кызлар һәм балалар гына калды. Ә тормышны алып барырга кирәк иде – игенен дә игәргә, балаларны да ач-ялангач итмәскә, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләп җибәрергә, гомер буе бетмәс төсле тоелган налогын да илтеп түләргә. Ләкин сез сынмадыгыз, сыгылмадыгыз.

Хәзер шул чорда сез яратып җырлаган җырларның берсен – «Уракчы кыз» ны ишетерсез. Нәкый Исәнбәт сүзләре, халык көе. Аны ... авылының сугыш һәм хезмәт ветераны *(Фәлән)* ага *(Фәләнов)* башкара. *(Җыр.)*

Хәзер шул еллар турында сөйләп китү өчен сүзне ... авылы ветераннары исеменнән пенсионер-укытучы *(Фәлән)* апага бирәбез. *(Фәлән апа сөйли.)*

**2 а.б.** Күпләрегез, корыч айгыр иярләп, тракторларга утырдыгыз. Ул тракторлар еш ватыла, әле бер механизмы туктап кала, әле башкасы сафтан чыга. Ә сабан артында – әле яңа гына сабыйлыктан чыгып килә торган япь-яшь кызлар. Ә хәзер ... авылы ветераннары исеменнән, сугыш вакытында механизатор булып эшләгән *(Фәлән)* апага сүз бирәбез. *(Фәлән апа сөйли.)*

**1 а.б.** Механизатор булып эшләгән хөрмәтле хатын-кызлар! Сезнең сөеклеләрегез, әтиләрегез, абыйларыгыз танкларга каршы атакага күтәрелсә, машиналар белән азык-төлек, корал ташыса, сез тимер айгырларыгыз белән җир сөрдегез, чәчтегез, сукаладыгыз. Һәм тылда икмәк җитештереп, фронтка озаттыгыз. Сез бу батырлыгыгыз белән Җиңү көнен якынайттыгыз. Рәхмәт сезгә!

**2 а.б.** Сезнең өчен *(Фәлән)* җырлый. *(Җыр яңгырый.)*

**1 а.б.**

Чабатадан, тездән суга батып,
Язгы чәчү җитәр алдыннан
Чыгып киткән икән симәнәгә
Хатын-кызлар безнең авылдан.
Сыерлары юлда ятып калган,
Җилкәләргә күчкән симәнә.
Бу турыда бүген сөйләгәндә
Әнкәй һаман елап җибәрә.
Кырык, илле чакрым язгы суда –
Кайталмасаң, илең ач кала.
Хатыннарда тик бер генә хәсрәт –
Һәр йорт саен көтә ач бала.

Әтиләрнең сугышып йөргән чагы,
Безнең яңа туган ел булган.
Капчык аскан егермеләп хатын
Басуларга кайтып егылган.
Орлык кайткан безгә гомер булып,
Без ни бирдек икән кайтарып?
...Әниләрнең әле яшәр чагы,
Китәләр шул иртә картаеп.
Бер шырпысыз түзгән, керосинсыз,
Чәй-шикәрсез түзгән авыл ул.
Сыер боты кадәр малайлары
Ил туйдыра – шундый авыл ул.
Тәпи йөрер-йөрмәс бала-чага
Бураздан билчән утаган.
Илгә – икмәк, авыл үзе өчен
Көлчә салган алабутадан.
Бер бәләкәй көлтә ега алган
Ул чорларның нужа хуҗасын.
Олылар күк күтәргән бит шулар
Ил хәсрәтен, Ватан нужасын.

**2 а.б.** Ә хәзер сезнең каршыгызга *(Фәлән)* әбине чакырабыз. *(Чыгыш.)*

**1 а.б.** Балачагын, яшьлекләрен сугыш урлаган, шулай да эштән арып кайткач, ач-ялангач килеш, су буйларында, кичке уеннарда, аулак өйләрдә күңел ачарга үзләрендә көч-дәрт тапкан сугыш чоры яшьләре өчен *(Фәлән)* җырлый. «Әйләнеп кайтыгыз». Рим Хәсәнов көе, Мансур Шиһапов сүзләре. *(Җыр.)*

**2 а.б.** Хөрмәтле тыл фидакарьләре! Авылда нинди эш булса, шуларның барысы да сезнең кулдан үткән. Ил язмышы да сезнең язмышыгыз иде. Шул чорларны искә алу өчен сүзне ... авылы ветераннары исеменнән ... булып эшләгән *(Фәлән)*гә бирәбез. *(Чыгыш.)*

**1 а.б.** Бөтен булган физик авырлыкларга түзәр идең әле, иң кыены авылларга кара пичәтле кәгазьләр агыла. Алма кебек хатыннар балаларын кочаклап ирсез, сабыйлар әтисез, җиләк кебек кызлар ярсыз калалар. Ләкин, хөрмәтле хезмәт ветераннары, сез сынып та, сыгылып та төшмәдегез. Тизрәк Җиңү килсен дигән теләк сезне тагын да тырышыбрак эшләргә өндәде. Бик зур рәхмәт сезгә!

*(Концерт номеры: темага туры килә торган шигырь укыла)*.

**2 а.б.** Сүзне ... ветераннары исеменнән пенсионер *(Фәлән)* апага бирәбез. *(Чыгыш.)*

**1 а.б.** Сугыш ятим иткән балалар, исән калган әтиләр кайтканда, сезнең йөрәкләр сыкрады, күзләргә яшь килде, башкаларның әтиләрен күргәндә: «Их, минем дә әтием исән булса иде», – дип авыр суладыгыз, башкалар «минем әти» дип сөйләгәндә сезнең «әти» дип авыз тутырып әйтер көнегезне каһәр суккан сугыш мәңгелеккә алып калган иде. Үз тырышлыклары белән сугыш бетүен якынайткан үсмерләр гомергә ятим булып калдылар.

Сезнең өчен *( Фәлән)* Альбина Имаеваның Роберт Миңнуллин сүзләренә язылган «Әткәм моңы» җырын башкара.

**2 а.б.** Сугыш беткәч тә, сез, тыл каһарманнары, төнне көнгә, көнне төнгә ялгап, эшләвегезне дәвам иттегез. Чөнки сугышка киткән ир-атларның яртысыннан күбесе һәлак булган, ә илдәге сугыш китергән хәрабәләрне торгызырга кирәк иде. Сез, ил язмышына кушылып, хезмәткә җигелдегез. Сезнең арада бик өлкән яшькә җиткәнчегә кадәр үз хезмәтләрен намус белән башкарган кешеләр байтак. Күпләрегез гаиләдә олы ихтирамлы кешеләр, балаларыгызның таянычы, оныкларыгызның юанычы. Сез әле дә олы йөрәкле, нык бәдәнле, саф күңелле әүлия затлар, сугыш чоры кешеләре. Тагын бер кат рәхмәт сезгә.

Халкыбызның «Сибелә чәчем» җырын *( Фәлән)* башкара. *(Җыр.)*

**1 а.б.**

Картаймагыз әле, ветераннар,
Картаймагыз, әй, тынгысыз җаннар!
Сезгә тиеш әле бик күп язлар,
Сезгә тиеш әле бик күп назлар.

*(Кичә тәмам)*.

## Эчтәлек

Кереш сүз һәм файдалану өчен чыганаклар,
методик ярдәмлекләр исемлеге ........................................................ 3

Татарстандагы хезмәт батырлыгы шәһәрләре ..................................... 8

Хезмәт батырлыгы предприятиеләре .................................................... 9

Хезмәт даны елъязмасы *(Әдәбият исемлеге)* ..................................... 11

Тыл батырлары – җиңү адымнары *(Кичә үткәрү планы)* .................. 14

Сезнең тормыш үзе батырлык *(Кичә сценарие)* ................................... 16

Басарга кул куелды 28.05.2026. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 75 данә. Заказ № 512.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе,
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86 йорт.

Подписано в печать 28.05.2026. Формат 60x84 1/16.
Тираж 75 экз. Заказ № 512.
Национальная библиотека Республики Татарстан,
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, д. 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.
420015, Казан шәһәре, К.Маркс ур., 36 йорт.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420015, г. Казань, ул. К.Маркса, д. 36.

